СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 48, 05.04.2016 ел
№ _________от ______________

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында
Саба муниципаль районы Уставында
үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты турында

2014 елның 19 декабрендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставын «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131 номерлы Федераль законга туры китерү һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Россия Федерациясе Федераль законының 44 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставы нигезендә һәм Саба муниципаль районы прокуратурасының күрсәтмәсен һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен яңа редакциядә карап, Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Саба муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставын яңа редакциядә кабул итү турында» 2014 елның 19 декабрендәге 281 номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
4. Саба муниципаль районы Советының юридик бүлеге башлыгы А.И. Миңнекаевка әлеге карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районы Башлыгы урынбасары Р.Р. Закирҗановка йөкләргә.

Саба муниципаль
муниципаль районы　　　　　　　　Р.Н. Минниханов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2016 елның 05 апрелендәге 48 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

**1.** 6 статьяның 1 пунктындагы 16 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16) Район территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым-аерым җыю), транспортировкалау, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда катнашу;»;

**2.** Уставның 6 статьясындагы 1 пунктының 17 пунктчасында «, шул исәптән сатып алу юлы белән,» сүзләрен төшереп калдырырга;

**3.** Уставның 6 статьясындагы 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 24.1 пунктча өстәргә:

«24.1) муниципаль район милкендәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) саклап калу, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру, муниципаль район территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) саклау;»;

**4.** 6 статьяның 1 пунктындагы 31 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

31) муниципаль район территориясендә физик культура, мәктәп спорты һәм массакүләм спорт үсеше өчен шартлар тудыру, муниципаль районның рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын уздыруны оештыру;»;

**5.** Уставның 6 статьясындагы 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 39 пунктча өстәргә:

«39) «күчемсез мөлкәтнең дәүләт кадастры турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкаруны оештыру һәм территориянең карта-планын раслау.»;

**6.** Уставның 6 статьясындагы 2 пунктының 13 пунктчасында «, шул исәптән сатып алу юлы белән,» сүзләрен төшереп калдырырга, «җирлек җирләреннән файдалануга муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру» сүзләрен «җирлек чикләрендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга;

**7.** 6 статьяның 2 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) җирлек чикләрендә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә электр, җылылык, газ белән тәэмин итүне оештыру;»;

**8.** 6 статьяның 2 пунктындагы 2 пунктчада «җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге» сүзләрен төшереп калдырырга;

**9.** 6 статьяның 2 пунктындагы 6) һәм 11 пунктчаларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

**10.** Уставның 6 статьясындагы 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 25 пунктча өстәргә:

«25) «Дәүләт күчемсез мөлкәт кадастры турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләрен башкаруда катнашу.»;

**11.** Уставның 19 статьясындагы 3 пунктының 4 пунктчасында «, монда «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә районны үзгәртеп кору өчен район халкының тавыш бирү юлы белән белдерелгән ризалыгын алу таләп ителгән очраклар керми» сүзләрен өстәргә;

**12.** Уставның 22 статьясындагы 4 пунктына «Татарстан Республикасы законы нигезендә» сүзләрен өстәргә;

**13.** Уставның 28 статьясындагы 6 пунктының 1 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

**14.** 28 статьяның 6 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, шулай ук хуҗалык итүче субъект белән идарә итүдә катнашырга (торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларыннан, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативларыннан, күчемсез милек милекчеләре ширкәтеннән һәм билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һөнәр берлекләреннән тыш), әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса яисә федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъекты законнары нигезендә муниципаль хокукый актта билгеләнгән тәртиптә аңа әлеге оешма белән идарә итүдә катнашу йөкләнмәгән булса;»;

**15.** Уставның 28 статьясындагы 6 пунктының 4 пунктчасының икенче җөмләсендә «граждан» сүзеннән соң «, административ» сүзен өстәргә;

**16.** Уставның 28 статьясындагы 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты, муниципаль вазыйфаны биләүче башка зат «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәргә тиеш. Депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты, муниципаль вазыйфаны биләп торучы башка зат вәкаләтләре 2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законда, 2012 елның 3 декабрендәге «Дәүләт вазыйфаларын биләүче һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору

турында» 230-ФЗ номерлы Федераль законда, 2013 елның 7 маендагы «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм аларны саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм(яки) алардан файдалануны тыю турында» 79-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән чикләү, тыю, бурычларны үтәмәгән очракта вакытыннан алда туктатыла.

**17.** Уставның 41 статьясындагы 4 пунктында «Совет составыннан» сүзләрен «Совет» сүзенә, «үз составыннан» сүзләрен төшереп калдырырга;

**18.** Уставның 45 статьясындагы 3 пунктының алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- район территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым-аерым җыю), транспортировкалау, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда катнаша;»;

**19.** Уставның 45 статьясындагы 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле унынчы абзац өстәргә:

«күчемсез мөлкәтнең дәүләт кадастры турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкаруны оештыру һәм территориянең карта-планын раслау.»;

**20.** 45 статьяның 5 пунктындагы унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- район территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итә, районның рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын уздыруны оештыра;»;

**21.** Уставның 45 статьясындагы 5 пунктына түбәндәге эчтәлекле унбишенче абзац өстәргә:

«- муниципаль район милкендә булган мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне) саклау, куллану һәм популярлаштыру, муниципаль район территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне) саклау буенча чаралар күрә;»;

**22.** 45 статьяның 9 пунктындагы икенче абзацында «, муниципаль хезмәт өчен кадрлар әзерләүне мәгариф турында Россия Федерациясе законнарында һәм муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә оештыра» сүзләрен өстәргә;

**23.** 47 статьяның 4 пунктында «Башкарма комитет» сүзләреннән соң «раслана» сүзләрен өстәргә;

**24.** 70 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 - 5 пунктлар өстәргә:

«3. Районны Татарстан Республикасы законы белән тиешле исемлеккә керткәндә, районның эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычлар билгели яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган бурычларны үзгәртүче муниципаль норматив хокукый акт проектлары Татарстан Республикасы законы нигезендә муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә, районның җирле үзидарә органнары тарафыннан үткәрелә торган җайга салу йогынтысында, түбәндәгеләрдән тыш, бәяләнергә тиеш:

1) район Советының җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләүче, үзгәртүче, туктатып торучы, юкка чыгаручы норматив хокукый актлары проектлары;

2) район Советының бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган норматив хокукый актлары проектлары.

4. Районны Татарстан Республикасы законы белән тиешле исемлеккә кертмәгәндә, районның эшмәкәрлек һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычлар билгели яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган бурычларны үзгәртүче муниципаль норматив хокукый акт проектлары Татарстан Республикасы законы нигезендә муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә, районның җирле үзидарә органнары тарафыннан үткәрелә торган җайга салу йогынтысында, түбәндәгеләрдән тыш, бәяләнергә тиеш:

1) район Советының җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләүче, үзгәртүче, туктатып торучы, юкка чыгаручы норматив хокукый актлары проектлары;

2) район Советының бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган норматив хокукый актлары проектлары.

5.Муниципаль норматив-хокукый актлар проектларын җайга салу йогынтысы ягыннан бәяләү эшмәкәрлек эшчәнлеге һәм башка икътисади эшчәнлек субъектлары өчен артык бурычлар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яки аларны кертүгә этәргеч бирә торган нигезләмәләрне ачыклау, шулай ук эшмәкәрлек эшчәнлеге һәм башка икътисади эшчәнлек субъектлары өчен һәм җирле бюджетларда нигезсез чыгымнар килеп чыгуга китерә торган нигезләмәләрне ачыклау максатыннан уздырыла.»;

**25.** Уставның 80 статьясындагы 2 пунктында «аларны акчалата тотуга чыгымнар» сүзләрен «аларның хезмәте өчен түләү чыгымнары» сүзләренә алмаштырырга.